# Татарстан Республикасы
# ЗАКОНЫ

## Китапханәләр һәм китапханә эше турында

Әлеге Закон Татарстан Республикасында китапханә эшен саклау һәм үстерүнең хокукый нигезен тәшкил итә . Ул китапханәләр эшчәнлегенең кешенең, җәмәгать берләшмәләренең, халыкларның һәм этник бергәлекләрнең ирекле рәвештә мәгълүмат алуга, ирекле рухи үсешкә, милли һәм дөнья мәдәнияте хәзинәләре белән танышуга, шулай ук мәдәни, фәнни мәгариф эшчәнлегенә хокукларын гарантияли торган принципларын билгели.

Әлеге Закон халыкара хокук принциплары һәм нормалары нигезендә китапханә эшен оештыру мәсьәләләрен, китапханә эше өлкәсендә дәүләт, гражданнар, юридик затлар арасындагы үзара мөнәсәбәтләрне җайга сала.

### I бүлек. Гомуми нигезләмәләр

1 статья. Төп төшенчәләр

Әлеге Законда түбәндәге төп төшенчәләр кулланыла:

китапханә - тиражланган документлардан оештырылган фондларга ия булган, аларны физик һәм юридик затларга вакытлыча файдалану өчен бирә торган мәгълүмати, мәдәни һәм белем бирү учреждениесе; Китапханә мөстәкыйль учреждение яисә юридик затның структур бүлекчәсе булырга мөмкин;

гомуми файдаланудагы китапханә - оештыру-хокукый һәм милек рәвешләренә карамастан, юридик затларга һәм, белемнәре

дәрәҗәсенә белгечлекләренә, дингә мөнәсәбәтләренә карап чикләмичә, гражданнарга үзенең фондларыннан һәм хезмәт күрсәтүләреннән файдалану мөмкинлеге бирүче китапханә;

китапханә фонды - китапханәдә булган, җәмәгатьчелек файдалануындагы һәм даими саклanudагы документлар җыеламасы;

китапханә эше - китапханәләр челтәрен төзү һәм үстерү, аларның фондларын формалаштыру һәм эшкәртү, китапханәләрдән файдаланучыларга китапханә, мәгълүмат һәм белешмә-библиография хезмәте күрсәтүне оештыру, кадрлар әзерләү, китапханәләр үсешен фәнни-ысулый тәэмин итү бурычларын үз эченә алган мәгълүмат, мәдәни-агарту һәм мәгариф эшчәнлеге тармагы;

документ - текст, тавышны язып алу яисә сурәт рәвешендәге мәгълүмат теркәлгән, вакыт һәм пространство эчендә саклау өчен һәм җәмәгатьчелек файдалануы өчен билгеләнгән матди объект;

документларның мәҗбүри нөсхәсе - аларны җитештерүчеләр тарафыннан законнарда билгеләнгән тәртиптә һәм санда тиешле учреждениеләргә һәм оешмаларга бирелергә тиешле төрле төрдәге тиражланган документларның нөсхәләре;

китапханәдән файдаланучы - китапханәләр хезмәтеннән файдаланучы физик яки юридик зат;

үзәкләштерелгән китапханә системасы - китапханәләрнең структур-бербөтен оешмага ихтыярый берләшүе;

китапханәнең иминләштерү фонды - китапханә фондының аеруча кыйммәтле документларны саклап калу максатында төзелгән өлеше.

<u>2 статья.</u> Татарстан Республикасының китапханә эше турындагы законнары

Китапханәләр һәм китапханә эше турындагы законнар әлеге Законнан һәм Татарстан Республикасының китапханә эше өлкәсендәге башка норматив-хокукый актларыннан тора.

<u>3 статья.</u> Әлеге Законның гамәлдә булу өлкәсе

Әлеге Закон Татарстан Республикасының Республика бюджеты һәм җирле бюджетлар акчалары исәбеннән тулысынча яки өлешчә финанслана торган дәүләт китапханәләренә, ә күпмилләтле Та-

тарстан Республикасы халыкларының мәдәни мирасы өлеше буларак китапханә фондларын саклау һәм алардан файдалану мәсьәләләрен җайга салу өлешендә - милек рәвешләренә карамастан, бөтен китапханәләргә кагыла.

4 статья. Китапханәләрнең төп төрләре

Китапханәләр дәүләт хакимияте һәм идарәсенең барлык дәрәҗәдәге органнары; җирле үзидарә органнары; иҗтимагый берләшмәләр; юридик һәм физик затлар тарафыннан гамәлгә куелырга мөмкин.

Китапханәләр түбәндәге төп төрләргә бүленәләр:

1. Дәүләт китапханәләре:

а) республика китапханәләре, шул исәптән:

Татарстан Республикасының Милли китапханәсе, республика балалар китапханәсе, республика яшүсмерләр китапханәсе, сукырлар өчен республика махсус китапханәсе;

б) коммуналь китапханәләр.

2. Җирле үзидарә органнары тарафыннан гамәлгә куелучы китапханәләр.

3. Хосусый китапханәләр.

4. Иҗтимагый берләшмәләрнең китапханәләре.

5. Чит илләрнең юридик һәм физик затлары тарафыннан, шулай ук халыкара оешмалар тарафыннан Татарстан Республикасының халыкара шартнамәләре нигезендә гамәлгә куелучы китапханәләр.

Китапханәләрне финанслау түбәндәгеләр исәбеннән башкарыла:

республика һәм җирле бюджетлар;

җирле үзидарә органнары акчалары;

иҗтимагый берләшмәләр акчалары;

юридик һәм физик затлар акчалары.

## II бүлек. Китапханә эше өлкәсендә гражданнарның хокуклары

5 статья. Китапханә хезмәтеннән файдалану хокукы

Татарстан Республикасының һәр гражданы, чыгышына, социаль һәм мөлкәти хәленә, нинди расадан һәм милләттән булуына, җенесенә, белеменә, теленә, сәяси карашларына, дини инануларына, шөгыленең төренә һәм үзенчәлегенә, тору урынына һәм башкаларга карамастан, Татарстан Республикасы территориясендә китапханә хезмәтеннән файдалану хокукына ия.

Гражданнарның китапханә хезмәтеннән файдалану хокукы түбәндәгеләр белән тәэмин ителә:

китапханә хезмәте күрсәтүнең төп төрләрен бушлай гамәлгә ашыручы гомуми файдаланудагы дәүләт һәм гомуми файдаланудагы җирле үзидарә китапханәләре челтәре булдыру;

дәүләт китапханәләре фондларын тулыландыруны һәм саклап калуны тәэмин итүче гарантияле финанслау;

күп төрле китапханәләр булдыру, оештыру-хокукый һәм милек рәвешләренә, эшчәнлекләренең юнәлешләренә һәм масштабларына бәйсез рәвештә китапханәләр оештыру эшендә юридик һәм физик затларга дәүләт ярдәме күрсәтү.

Китапханә хезмәте күрсәтү өлкәсендә гражданнарның хокуклары дәүләт, аның теләсә кайсы структурасы, сәяси фиркаләр, иҗтимагый берләшмәләр һәм башка оешмаларның бу өлкәдәге хокукларына карата өстенрәк була.

6 статья. Китапханә эшчәнлегенә хокук

Теләсә кайсы юридик яки физик зат законнар нигезендә Татарстан Республикасы территориясендә китапханә оештырырга хокуклы.

Гражданнар попечительләрнең, китап укучыларның советларында яки китап укучыларның китапханәләр яисә аларны гамәлгә куючылар җитәкчеләренең ризалыгы белән оештырылган башка төрле берләшмәләре эшчәнлегендә катнашырга хокуклы.

Китапханә хезмәткәрләре, китапханә хезмәте күрсәтүне үстерүгә, һөнәри берләшүгә, үзләренең социаль һәм һөнәри мәнфә-

гатьләрен яклауга ярдәм итү максатында иҗтимагый берләшмәләр төзергә хокуклы.

Хосусый милек хокукында саклანучы тарихи, мәдәни ядкярләргә караган аеруча әһәмиятле басмалар һәм тупланмалар рәвешендәге документлар җыелмасына ия булган гражданнар бу тупланмаларны тарихи һәм мәдәни ядкярләр сыйфатында республиканың тиешле дәүләт органында яисә җирле үзидарә органында теркәгән очракта аларның сакланылышын тәэмин итү өчен дәүләттән ярдәм алырга хокуклы.

7 статья. Китапханәләрдән файдаланучыларның хокуклары

Китапханәләрдән барлык файдаланучылар да китапханәләргә йөрергә, үз ихтыяҗлары һәм мәнфәгатьләре нигезендә аларны ирекле сайларга хокуклы. Мәгълүмат алу, алардан файдалану кагыйдәләре, күрсәтелә торган төп хезмәтләр исемлеге һәм шартлары законнар һәм китапханә уставы белән билгеләнә. Китапханәләрдән файдаланучы китапханә фондларында конкрет документның булуы яки булмавы хакындагы мәгълүматны теләсә кайсы китапханәдән бушлай алырга хокуклы.

Гомуми файдаланудагы китапханәләрдә гражданнар түбәндәге хокукларга ия:

шәхесләрен раслаучы документлар күрсәтеп, китапханәләрдән файдаланырга, 16 яшькә җитмәгән балигъ булмаганнар - аларның законлы вәкилләренең шәхесләрен раслаучы документлар күрсәтеп, китапханәләрдән файдаланырга;

каталоглар системасы һәм китапханә мәгълүматының башка рәвешләре аша китапханә фондлары составы турында бушлай тулы мәгълүмат алырга;

мәгълүмат чыганакларын эзләүдә һәм сайлауда бушлай консультатив ярдәм алырга;

китапханәара һәм халыкара абонемент хезмәтләреннән файдаланырга;

китапханәдән файдалану кагыйдәләре нигезендә вакытлыча файдалану өчен китапханә фондларыннан теләсә кайсы документны түләүсез алырга;

башка төр хезмәтләрдән, шул исәптән китапханәдән файдалану кагыйдәләрендә каралган исемлек нигезендә түләүле хезмәт-

ләрдән файдаланырга.

Дәүләт китапханәләрендә һәм җирле үзидарә органнары тарафыннан гамәлгә куелган китапханәләрдә китапханәләрдән файдаланучылар документларны Татарстан Республикасының дәүләт телләрендә алырга һәм дәүләт телләрендә хезмәт күрсәтелүгә хокуклы.

Китапханәдән файдаланучы үз хокукларын чикләүгә китергән гамәлләренә карата китапханәләрнең урындагы затларына законда билгеләнгән тәртиптә шикаять белдерергә мөмкин.

8 статья. Китапханәләрдән файдаланучы аерым төркемнәрнең хокуклары

Сукырлар һәм начар күрүчеләр дәүләтнең махсус китапханәләрендә һәм башка гомуми файдаланудагы китапханәләрдә махсус чаралар ярдәмендә мәгълүмат теркәлгән документлар аша китапханә хезмәте күрсәтелүгә хокуклы.

Өлкән яшькә җитүләре һәм физик кимчелекләре аркасында китапханәләргә йөри алмаган файдаланучылар гомуми файдаланудагы китапханәләр фондларыннан документларны стационардан тыш һәм читтән торып хезмәт күрсәтү рәвешендә алырга хаклы.

Китапханәләрдән файдаланучы балалар һәм үсмерләр, әлеге китапханәләрнең уставлары һәм кагыйдәләре нигезендә гомуми файдаланудагы китапханәләрдән, балалар һәм үсмерләрнең махсус дәүләт китапханәләреннән, шулай ук мәгариф учреждениеләре китапханәләреннән хезмәт күрсәтелүләргә хокуклы.

9 статья. Китапханәләрдән файдаланучыларның җаваплылыгы

Файдаланучылар китапханәләрдән файдалану кагыйдәләрен үтәргә тиеш.

Файдалану кагыйдәләрен бозган һәм зыян китергән файдаланучылар, китапханәләрдән файдалану кагыйдәләрендә билгеләнгән күләмдә зыянны түлиләр, шулай ук законнарда каралган очракларда башка җаваплылыкка тартылалар.

167



## III бүлек. Китапханәләрнең бурычлары һәм хокуклары

### 10 статья. Китапханәнең статусы

Дәүләт китапханәләре, җирле үзидарә органнары китапханәләре, үзәкләштерелгән китапханәләр системалары законнарда билгеләнгән тәртиптә теркәү мизгеленнән башлап юридик зат статусы алалар. Башка китапханәләрнең статусын аларны гамәлгә куючылар билгели.

### 11 статья. Китапханәләрнең бурычлары

Китапханәләр үз эшчәнлекләрендә гражданнарның әлеге Законда билгеләнгән хокукларын гамәлгә ашыруны тәэмин итәләр. Китапханәләр китапханәләрдән файдаланучыларга законнар, үзләренең уставлары, китапханәләрдән файдалану кагыйдәләре нигезендә хезмәт күрсәтәләр.

Китапханәләрдән файдаланучыларның китапханә фондларыннан файдалану иреген кыса торган дәүләт цензурасына яки башка төрле цензурага, шулай ук китапханәләрдән файдаланучылар һәм укучыларның таләпләре хакында мәгълүматлардан, фәнни максатларда һәм китапханә хезмәте күрсәтүне оештыру өчен файдалану очракларыннан тыш, файдалануга юл куелмый.

Китапханәләр түбәндәгеләрне үтәргә тиеш:

китапханә фондларын, беренче чиратта аларның аеруча зур кыйммәткә ия булганнарын, милли һәм мәдәни байлыклар рәтенә кертелгән җирле документларны һәм Татарстан Республикасының дәүләт телләрендәге һәм Татарстан Республикасының башка халыклары телләрендәге документларны саклауны тәэмин итәргә;

документларны саклау һәм алардан файдалану режимын үтәргә;

законнарда һәм китапханәләрнең гамәлгә кую документларында билгеләнгән тәртиптә статистика хисабын алып барырга;

үз эшчәнлекләрендә җәмгыятьтә килеп туган идеологик һәм сәяси күптөрлелекне чагылдырырга;

үзләренең һөнәри эшчәнлекләре хакында гамәлгә куючылар алдында хисап бирергә;

китапханәдән файдаланучыларның таләбе буенча аларга фонд-

168



ларны формалаштыру һәм файдалану юнәлешендә үз эшчәнлекләре хакында мәгълүмат бирергә.

12 статья. Китапханәләрнең хокуклары

Китапханәләр түбәндәгеләргә хокуклы:

үз уставларында күрсәтелгән максатлар һәм бурычлар нигезендә һөнәри эшчәнлекләренең эчтәлеген һәм рәвешләрен мөстәкыйль билгеләргә;

гамәлгә куючылары белән килештереп, китапханәләрдән файдалану кагыйдәләрен расларга;

сирәк очрый торган һәм кыйммәтле басмалардан файдаланган өчен һәм шулай ук китапханәләрдән файдалану кагыйдәләрендә каралган башка очракларда залог алу суммасын билгеләргә;

китапханәләрдән файдаланучылар китергән зыянны түләттерү төрләрен һәм күләмнәрен билгеләргә;

файдаланучыларга тәкъдим ителә торган хезмәт күрсәтүләрнең исемлеген киңәйтү һәм, төп эшчәнлекләренә зыян китермәслек булса, китапханәләрнең социаль-иҗади мөмкинлекләрен арттыру максатында эшкуарлык эшчәнлеге белән шөгыльләнергә;

юридик һәм физик затлар белән төзелгән шартнамәләр нигезендә хезмәт күрсәтүләрнең шартларын билгеләргә;

законнарда каралган тәртиптә ассоциацияләргә (берлекләргә) берләшергә;

чит илләрнең китапханәләре һәм башка учреждениеләре белән хезмәттәшлек итәргә, халыкара китап алмашырга, тиешле тәртиптә халыкара оешмаларга керергә, халыкара китапханә һәм башка программаларны гамәлгә ашыруда катнашырга;

үз фондларын туплау чыганакларын мөстәкыйль билгеләргә;

гамәлдәге норматив-хокукый актлар нигезендә төзелгән һәм китапханәләрне гамәлгә куючылар белән килештерелгән документларны исәптән төшерү тәртибенә таянып, үз фондларыннан, мәдәни һәм тарихи ядкярләр рәтенә кертелгән документлардан кала, башка документларны алырга һәм сатарга;

законнарга каршы килмәгән башка гамәлләр калырга.

Китапханәләр китап нәшер итүнең федераль һәм республика программалары буенча чыгарылучы документларны, ябыла торган китапханәләрнең документларын беренче чиратта сатып алуга за-

169



коннар нигезендә өстенлекле хокукка ия.

### IV бүлек. Дәүләтнең китапханә эше өлкәсендәге бурычлары

13 статья. Дәүләтнең китапханә эше өлкәсендәге бурычлары

Татарстан Республикасының китапханә өлкәсендәге дәүләт сәясәте төрле типтагы китапханәләрне һәм халыкка китапханә хезмәте күрсәтүнең төрле рәвешләрен үстерүне күздә тота, китапханә фондларында тупланган мәгълүматларның һәм мәдәни кыйммәтләрнең һәр кеше файдалана алырлык булу принцибына нигезләнә.

Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте һәм идарәсе органнары аша әлеге Законда каралган хокукларны гарантияли һәм, законнарда каралган очраклардан кала, китапханәләрнең һөнәри эшчәнлегенә тыкшынмый.

Дәүләт хакимияте һәм идарәсе органнарының бюджеттан финансланучы гамәлдәге китапханәләрне матди-техник тәэмин итүне начарайтуга китерә торган карарлар кабул итәргә һәм гамәлләр кылырга, аларны хезмәт иминлеге, китапханә фондларын саклау һәм китапханә хезмәте күрсәтү таләпләренә җавап бирми торган биналарга күчерергә хокукы юк.

Әлеге органнарның, шулай ук аларның урындагы затларының китапханәләр һәм алардан файдаланучыларның законлы мәнфәгатьләрен боза торган карарлары һәм гамәлләре хакында законнарда билгеләнгән тәртиптә шикаять белдерелергә мөмкин.

14 статья. Дәүләтнең китапханә эшен үстерүдәге бурычлары

Татарстан Республикасы тиешле дәүләт хакимияте һәм идарәсе органнары аша түбәндәгеләрне тәэмин итә:

1) китапханә эше өлкәсендә дәүләт сәясәтен билгеләү һәм китапханәләр эшчәнлеген җайга сала торган законнар һәм башка норматив-хокукый актлар кабул итүне; китапханә эшен үстерү буенча республика программаларын эшләүне, китапханә эшен үстерү мәсьәләләрен республиканың башка программаларына кертүне;

2) Татарстан Республикасының Республика бюджеты кысала-

170



рында дәүләт китапханәләрен финанслауга юнәлдерелүче чыгымнар суммасын раслауны;

3) дәүләт китапханә стандартлары һәм нормативларының саклануына контрольлек итүне;

4) китапханә хезмәткәрләрен әзерләү, яңа һөнәргә өйрәтү, аларның белемнәрен һәм квалификацияләрен күтәрү белән шөгыльләнүче уку йортлары эшчәнлегенә идарә итүне;

5) бердәм китапханә статистикасын оештыруны, аның дөреслеген, вакытында керүен һәм һәр кеше әчен ачык булуын тәэмин итүне;

6) китапханә эше өлкәсендә фәнни тикшеренүләргә, аларны ысулый тәэмин итүгә һәм финанслауга булышлык күрсәтүне;

7) дәүләт китапханәләрен максатчан финанслауны, аларны өстенлекле шартларда биналар һәм йортлар белән тәэмин итүне;

8) китапханәләргә китап туплауны тәэмин итә торган китап нәшер итүче һәм китап сәүдәсе белән шөгыльләнүче оешмалар эшчәнлеген кызыксындыруны;

9) дәүләт китапханәләренең фондларын туплауны гарантияле финанслауны һәм аларны саклауны;

10) китапханәләрне нормативларга туры килә торган биналар, заманча механикалаштыру һәм автоматлаштыру чаралары, җиһазлар һәм транспорт белән.

Дәүләт хакимияте һәм идарәсенең тиешле органнары законнар нигезендә китапханәләргә салымнар һәм җыемнар буенча өстенлекле ташламалар бирә алалар.

## V бүлек. Китапханә эше өлкәсендә Татарстан Республикасы халыкларының мәдәни казанышларын саклауның һәм алардан файдалануның аерым шартлары

### 15 статья. Татарстан Республикасы халыкларының мәдәни казанышы буларак китапханә фондлары

Архив документлары, борынгы һәм сирәк очрый торган китаплар, кабатланмас библиографик хәзинәләр, китапханә коллекцияләре һәм җыелмалары тупланган китапханә фондлары күчемле мәдәни һәм тарихи хәзинәләргә керәләр һәм законнар нигезендә файдаланылалар.

171



фондларында мәдәни һәм тарихи хәзинәләр сыйфатында теркәлгән объектлар булган китапханәләр бетерелгәндә, шулай ук аларны саклау һәм файдалану шартлары үтәлмәгәндә, бу хәзинәләр, алга таба аларны файдалануны саклауны һәм файдалануны тәэмин итү өчен, тарихи һәм мәдәни ядкярләрне саклау белән шөгыльләнүче дәүләт органы белән килештереп, фонд милекчесе карары белән алардан алынырга һәм башка китапханәгә тапшырылырга мөмкин.

Китапханә фондларына кергән һәм дәүләт архив фондының бер өлешен тәшкил иткән кульязма материаллар законнарда каралган тәртиптә саклаlaraлар һәм файдаланылалар.

## 16 статья. Китапханә фондларындагы документларны исәпкә алу, саклау һәм аерып алу

Китапханә фондларындагы документларны исәпкә алу, саклау һәм юкка чыгару законнар һәм башка норматив-хокукый актлар нигезендә гамәлгә ашырыла.

Документларны саклау һәм озак вакыт файдалану максатларында Татарстан Республикасында китапханә иминият фондлары төзелә.

Чыга башлаган көннәреннән алып җирле көндәлек матбугат басмалары, Татарстан Республикасының тарихи һәм мәдәни ядкярләренә кертелүче кыйммәтле һәм сирәк очрый торган басмалар мәҗбүри тәртиптә китапханәнең иминият фондларына кертеләләр.

Китапханә фондларын саклау режимын тәэмин итәрлек бинаны гамәлгә куючы бирергә тиеш.

Китапханәләр Татарстан Республикасының дәүләт телләрендәге һәм алар хезмәт күрсәтә торган төбәкләрдә яшәүче халыклар телләрендәге, шулай ук чит телләрдәге әдәбияттан туплана.

Китапханәләр, документларның мәҗбүри нөсхәләреннән гайре, документлар сатып алу чыганакларын ирекле рәвештә сайлыйлар.

Китапханә фондларын туплау:

законнарда билгеләнгән тәртиптә һәм санда мәҗбүри нөсхәләр алу нигезендә;

акчалата түләп һәм акчасыз исәп-хисап ясау аша сатып алу юлы белән;

китап алмашу рәвешендә;

физик һәм юридик затлардан иганә рәвешендә һәм бушлай тапшыру юлы белән гамәлгә ашырыла.

Татарстан Республикасының дәүләт китапханәләре китапханә фондларына документлар алуда өстенлекле хокукка ия.

## VI бүлек. Китапханәләрнең үзара хезмәттәшлеген оештыру

17 статья. Китапханә хезмәте күрсәтүне координацияләүне һәм кооперацияләүне тәэмин итүдә дәүләтнең катнашуы

Китапханә фондларыннан нәтиҗәле файдалану максатларында һәм китапханәләрдән файдаланучыларның мәгълүматка ихтыяҗларын тулырак канәгатьләндерү өчен дәүләт аларның ресурсларыннан бергәләшеп файдалануны кызыксындыра, гомуми китапханәләр ресурсларыннан (китапханәара һәм халыкара абонементтан, җыелма каталоглардан, автоматлаштырылган мәгълүмат базаларыннан, депозитарийлардан һәм телекоммуникация челтәрләреннән) бергәләшеп файдалану өчен шартлар тудыру эшчәнлеген финанслый.

18 статья. Үзәк китапханәләр

Китапханәләргә үзәк китапханә статусы бирелергә мөмкин, аның вазыйфаларын түбәндәге китапханәләр үти:

а) Татарстан Республикасында:

Татарстан Республикасы Милли китапханәсе;

Республика яшүсмерләр китапханәсе;

Республика балалар китапханәсе;

Сукырлар өчен махсус республика китапханәсе;

б) шәһәрдә - үзәк шәһәр китапханәсе;

в) районда - үзәк район китапханәсе.

Үзәк китапханәләр үзләре хезмәт күрсәтә торган территория чикләрендә документларның тулырак универсаль җыелмасын саклыйлар һәм файдаланучыларга тәкъдим итәләр, китапханә ресурсларыннан бергәләшеп файдалануны оештыралар һәм бүтән китапханәләргә ысулый ярдәм күрсәтәләр.

Тармак принцибы, файдаланучыларның аерым төркемнәренә хезмәт күрсәтү принцибы буенча бүленгән үзәк китапханәләр Та-

тарстан Республикасының дәүләт хакимияте һәм идарәсе органнары, җирле үзидарә органнары тарафыннан төзелергә мөмкин.

**19 статья.** Китапханәләрнең фәнни-техник мәгълүмат органнары һәм архивлар белән үзара хезмәттәшлеге

Дәүләт мәгълүмат ресурсларыннан нәтиҗәле файдалануны тәэмин итү өчен китапханәләр фәнни-техник мәгълүмат органнары, архивлар, музейлар, төрле дәрәҗәдәге мәгълүмат базалары белән хезмәттәшлек итәләр. Хезмәттәшлек тәртибе законнар, дәүләт программалары, шулай ук әлеге оешмалар арасында төзелгән шартнамәләр белән билгеләнә.

Университетларның, академияләрнең, институтларның китапханәләре тармаклар буенча һәм документларның махсуслаштырылган тулырак җыелмаларын барлыкка китерәләр, саклыйлар һәм файдаланучыларга тәкъдим итәләр.

## VII. Татарстан Республикасының милли китапханәсе

**20 статья.** Татарстан Республикасының Милли китапханәсенең юридик статусы

Татарстан Республикасы Милли китапханәсе юридик зат була, аның мөстәкыйль балансы һәм Татарстан Республикасы Министрлар кабинеты раслаган үз уставы була.

Татарстан Республикасы Милли китапханәсенең бинасы һәм башка мөлкәте Татарстан Республикасы Милли китапханәсенә оператив идарә итү хокукында беркетелә. Татарстан Республикасы Милли китапханәсен, шулай ук аның корылмаларын һәм бинасын хосусыйлаштыру тыела.

Татарстан Республикасы Милли китапханәсе эшчәнлеген финанслау Татарстан Республикасының Республика бюджетыннан, шулай ук финанслауның башка чыганакларыннан законнар нигезендә гамәлгә ашырыла.

Татарстан Республикасы Милли китапханәсенең финанс чараларын файдалану тәртибе аның уставы белән регламентлана.

21 статья. Татарстан Республикасының Милли китапханәсе эшчәнлеге юнәлешләре

Татарстан Республикасы Милли китапханәсе - милли һәм республика, Россия һәм чит илләр матбугаты саклана торган баш дәүләт китап саклагычы, күп функцияле китапханә-мәгълүмати һәм фәнни-тикшеренү учреждениесе, мәдәни, библиографик, ысулый үзәк.

Татарстан Республикасы Милли китапханәсе Татарстан халыклары мәдәни мирасының аеруча кыйммәтле объектларына кертелә. Аның фонды республиканың мәдәни һәм фәнни байлыгын киләчәк буыннар өчен саклауны тәэмин итеп, мемориаль әһәмияткә ия була.

Татарстан Республикасы Милли китапханәсе түбәндәге вазыйфаларны башкара:

илебездә һәм чит илләрдә әзерләнгән документларның иң тулы җыелмасын барлыкка китерә, саклый һәм файдаланучыларга тәкъдим итә;

республика территориясендә һәм аннан читтә басылган иң тулы җыелмасын туплау һәм аларны мәңгелек саклау принципларында туган як һәм татар әдәбиятының фондын барлыкка китерә;

Татарстан Республикасы турындагы милли матбугатның һәм документларның, Россия һәм чит ил документларының библиографик исәбен алып бара;

милли библиография тәзи;

җәмгыятьнең универсаль мәгълүмат ихтыяҗларын канәгатьләндерә;

Татарстан Республикасы китапханәләре эшчәнлегенә фәнни-ысулый җитәкчелек итә;

Татарстан Республикасы Дәүләт Советының, Татарстан Республикасы Президентының, Татарстан Республикасы Министрлар кабинетының эшчәнлеген мәгълүмат һәм китапханә ягыннан тәэмин итә;

республикада китапханә эшен камилләштерү буенча фәнни тикшеренүләр уздыра;

ысулый ярдәм күрсәтә, Россия Федерациясе субъектларының татар диаспорасы вәкилләренә хезмәт күрсәтә торган китапханәләрен туган як турындагы һәм татар әдәбияты белән тулыландыруда булышлык итә;

китапханә эше өлкәсендә дәүләт сәясәтен эшләүдә һәм гамәлгә ашыруда катнаша.

Татарстан Республикасы Милли китапханәсе, фән һәм мәгариф учреждениеләре, республиканың башка китапханәләре белән берлектә, республикада китапханә эшен үстерү программалары, стандартлар һәм нормалар, китапханә эшчәнлеген җайга сала торган башка документлар эшләүдә катнаша.

Татарстан Республикасының Милли китапханәсе фонды түбәндәгеләр нигезендә туплана:

документларның мәҗбүри федераль һәм республика нөсхәләре системасы, бу очракта документ җитештерүче һәр зат аңа документларның бушлай икешәр мәҗбүри нөсхәсен җибәрергә тиеш;

китапханә илебезнең һәм чит илләрнең сәүдә системасы, шулай ук арадашчы оешмалар һәм аерым затлар аша турыдан-туры түләү һәм күчерү юлы белән исәп-хисаплар ясап документлар сатып алу;

үз илебезнең китапханәләре һәм чит ил китапханәләре белән китап алмашу;

аларны бүләк рәвешендә алу;

башка чыганаклар.

## VIII бүлек. Китапханә эше өлкәсендә икътисадый җайга салу

### 22 статья. Китапханәне гамәлгә куючы

Мөлкәт милекчеләре яисә алар тарафыннан вәкаләтләр бирелгән физик яки юридик затлар китапханәләрнең гамәлгә куючылары була алалар.

Китапханәне гамәлгә куючы аның эшчәнлеген финанслый һәм әлеге эшчәнлекне тикшереп тора, шулай ук китапханә җитәкчесен билгеләп куя.

Китапханәне гамәлгә куючы аның уставын раслый, аны финанслау, матди-техник тәэмин итү буенча үз өстенә йөкләмә ала. Китапханә уставында аның юридик статусы, финанслау чыганаклары, эшчәнлегенең төп бурычлары, аннан файдалану шартлары, китапханә белән аның гамәлгә куючысы арасындагы мөлкәти мөнәсәбәтләр, китапханә белән идарә итү тәртибе беркетелергә тиеш.

гамәлгә куючы, законнарда һәм китапханә уставында каралган очраклардан гайре, китапханәнең иҗади эшчәнлегенә тыкшына алмый.

Китапханә белән аны гамәлгә куючысы арасындагы мөлкәти һәм финанс мөнәсәбәтләре законнар һәм гамәлгә кую документлары нигезендә җайга салына.

23 статья. Китапханәләрне үзгәртеп кору һәм ябу

Китапханә законнарда каралган нигездә үзгәртеп корылырга яки ябылырга мөмкин.

24 статья. Китапханәләр мөлкәте

Дәүләт китапханәсе оператив идарә итү хокуклары нигезендә үзенә беркетелгән мөлкәтне били һәм аннан файдалана.

Дәүләт китапханәләре, җирле үзидарә органнары китапханәләре һәм башка гомуми файдаланудагы китапханәләр халыкка китапханә хезмәте күрсәтүне яхшырту өчен файдалану максатында законнарда билгеләнгән тәртиптә җир кишәрлекләре һәм җитештерү биналары алырга хокуклы.

Китапханәнең финанс чараларыннан файдалану тәртибе аның уставы белән регламентлана.

Агымдагы хисап чорында файдаланылмаган акчалар тартып алынмыйлар һәм киләчәктә алар устав максатларында файдаланылалар.

25 статья. Китапханәләрне үстерү фондлары

Барлык милек рәвешләрендәге китапханәләрнең эшчәнлеген матди тәэмин итүгә булышлык күрсәтү максатларында китапханәләрне үстерүнең дәүләт фондлары, дәүләткә карамаган фондлары оештырылырга мөмкин. Аларны туплау чыганагын әлеге фондларны гамәлгә куючыларның кертемнәре, юридик затларның кертемнәре, гражданнардан һәм җәмәгать берләшмәләреннән керә торган хәйрия кертемнәреннән, махсус лотереяләр, аукционнар уздырудан, башка коммерция гамәлләреннән алына торган табышлар тәшкил итә.

Күрсәтелгән фондларның акчалары китапханә эшен үстерү программаларын финанслау, китапханәләр эшчәнлеген координацияләү һәм кооперацияләү максатларында, әлеге фондларның гамәлгә куючылары тарафыннан расланучы уставларында каралган тәртиптә башка гамәлләрне финанслау өчен файдаланыла. Китапханәләрне үстерү фондларының акчалары, милек рәвешләренә карамастан теләсә кайсы китапханәнең эшчәнлеген кызыксындыру максатларында да файдаланырга мөмкин.

26 статья. Китапханә хезмәткәрләренең хезмәт мөнәсәбәтләре

Китапханә хезмәткәрләренең хезмәт мөнәсәбәтләре хезмәт турындагы законнар белән җайга салына.

Китапханә хезмәткәрләре даими рәвештә аттестация узарга тиеш, аны уздыруның тәртибе һәм шартлары Татарстан Республикасы Министрлар кабинеты тарафыннан билгеләнә.

Китапханә хезмәткәрләренә эшләгән еллары өчен белгечлек буенча эш стажына бәйле рәвештә хезмәт хакыннан түбәндәге күләмнәрдә өстәмәләр билгеләнә:

эш стажы 5 елдан 10 елга кадәр булганда - 20 процент, 10 елдан 15 елга кадәр булганда - 25 процент, 15 елдан 20 елга кадәр булганда - 30 процент, 20 елдан 25 елга кадәр булганда - 35 процент, 25 елдан артык булганда - 40 процент.

Китапханәләр хезмәт өчен түләүгә үз средстволары чикләрендә үзләренең хезмәткәрләренә хезмәт өчен түләү рәвешен һәм системасын, өстәмәләр һәм өстәлмәләр, премияләр һәм башка кызыксындыру түләүләре күләмен мөстәкыйль билгелиләр.

Дәүләт хакимияте һәм идарәсенең җирле органнары, предприятиеләр һәм оешмалар, иҗтимагый берләшмәләр үз ресурслары исәбеннән китапханә хезмәткәрләренә өстәмә рәвештә өстенлекле ташламалар билгели алалар.

## IX бүлек. Әлеге Законны бозган өчен җаваплылык

27 статья. Әлеге Законны бозган өчен җаваплылык

Юридик һәм физик затларның "Китапханәләр һәм китапханә эше турында" Татарстан Республикасы Законын боза торган гамәлләре законнар нигезендә җаваплылыкка китерә.

## X бүлек. Әлеге Законны гамәлгә кертү турында

28 статья. Әлеге Законны гамәлгә кертү турында

Әлеге Законны матбугатта басылып чыккан көненнән гамәлгә кертергә.

Әлеге Законның 26 статьясындагы 3 өлешен 2000 елның 1 гыйнвареннан гамәлгә кертергә.

Татарстан Республикасы
Президенты М.Шәймиев

Казан шәһәре,
1998 елның 21 октябре
№ 1818